10 нчы октябрь 2013 нчы ел    Казан ш.    6-26/тп №лы

***Татарстан Республикасы территориясында капиталь төзелеш объектының җылыту йөкләнеше сәгатенә 0,1 гигакаллориядан артмый торган җылыту системаларына тоташу өчен гариза бирүчеләргә түләү билгеләнүе турында***

«Җылы белән тәэмин итү турында» 27 нче июль 2010 190-ФЗ №лы Федераль законы, «Җылыту системаларына тоташу тәртибе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәртүләр кертү турында» 16 нчы апрель 2012 307№лы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләнүе турында» 22 октябрь 2012 1075 №лы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә көйләүле бәяләрнең (тарифларның) исәп-хисабы буенча методик күрсәтмәләренең раслануы турында» 13 июнь 2013 760-э №лы әмере, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы территориясында капиталь төзелеш объектының җылыту йөкләнеше сәгатенә 0,1 гигакаллориядан артмый торган җылыту системаларына тоташу өчен гариза бирүчеләргә (НДС белән) 550 сум күләмендә түләү билгеләргә.
2. Җылы белән тәэмин итү (җылылык челтәре) оешмаларына җылыту системаларына тоташу чараларын үткәрүенә кагылышлы керем-чыгымнарын аерым исәп-хисаплауны алып баруны тәэмин итергә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән сон ун көн эчендә көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты  Рәисе вазифасын башкаручы    А.Л. Штром